**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 май № 330

г. Казань

Татарстан Республикасында студентларның хезмәт отрядларына булышлык күрсәтүгә һәм аларны үстерүгә юнәлтелгән социаль әһәмияттәге проектларны тормышка ашыра торган коммерциячел булмаган оешмаларга грантлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасында студентларның хезмәт отрядлары яшьләр хәрәкәтен үстерү өлкәсендә дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында студентларның хезмәт отрядларына булышлык күрсәтүгә һәм аларны үстерүгә юнәлтелгән социаль әһәмияттәге проектларны тормышка ашыра торган коммерциячел булмаган оешмаларга грантлар бирү тәртибен расларга (теркәлгән).
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 20 май, 330 нчы
карары белән расланды

# Татарстан Республикасында студентларның хезмәт отрядларына булышлык күрсәтүгә һәм аларны үстерүгә юнәлтелгән социаль әһәмияттәге проектларны тормышка ашыра торган коммерциячел булмаган оешмаларга грантлар бирү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасында студентларның хезмәт отрядларына булышлык күрсәтүгә һәм аларны үстерүгә юнәлтелгән социаль әһәмияттәге проектларны тормышка ашыра торган коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар (алга таба – КБО, грантлар) бирү кагыйдәләрен билгели.

1.2. Грантлар бирүнең максаты – Татарстан Республикасында студентларның хезмәт отрядлары хәрәкәтен үстерүгә юнәлтелгән социаль әһәмияттәге проектларны тормышка ашыру, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә яшьләрнең икенче хезмәт белән тәэмин ителешен оештырганда мәсьәләләрне хәл итүдә дәүләт хакимияте һәм КБО органнарының үзара эш итү формаларын камилләштерү, граждан җәмгыяте институтларын үстерүдә КБО ролен күтәрү.

1.3. Грантлар бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында студентлар һәм яшьләрнең хезмәт отрядлары эшчәнлеген үстерү концепциясен раслау турында» 2014 ел, 25 июль, 537 нче карары белән расланган 2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында студентлар һәм яшьләрнең хезмәт отрядлары эшчәнлеген үстерү концепциясе чараларын тормышка ашыруга тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре кысаларында гамәлгә ашырыла.

1.4. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

грант бирүче – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

вәкаләтле орган – грантлар бирүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;

конкурс – грантлар бирү өчен конкурс нигезендә КБО сайлау процедурасы;

конкурс комиссиясы –конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен вәкаләтле орган тарафыннан оештырылган комиссия;

конкурста катнашучылар – конкурста катнашу рөхсәт ителгән КБО;

грант алучылар – конкурс җиңүчеләре дип танылган һәм грант бирү турында вәкаләтле орган белән килешү төзегән КБО.

## 2. Конкурсны үткәрү тәртибе

2.1. Конкурс үткәрелү турында мәгълүмат вәкаләтле орган тарафыннан конкурс үткәрү турында карар кабул ителгән көннән соң өч эш көне эчендә вәкаләтле органның рәсми сайтында http://mdms.tatarstan.ru/ (алга таба – сайт) урнаштырыла.

2.2. Конкурста катнашу Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм заявка биргән көнгә кадәр кимендә бер ел Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы КБО рөхсәт ителә.

2.3. Конкурста катнашу өчен КБО вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

а) әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтадагы форма буенча заявка;

б) дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе;

в) оешма мөһере һәм җитәкче имзасы белән таныкланган устав күчермәсе;

г) заявкалар кабул итү вакыты башланганчы өч айдан да иртә бирелмәгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә күчермәсе;

д) әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтадагы форма буенча Татарстан Республикасында студентларның хезмәт отрядларына булышлык күрсәтүгә һәм аларны үстерүгә юнәлтелгән социаль әһәмияттәге проект тасвирламасы;

е) тапшырылган документлар исемлеге.

2.4. КБО конкурска бердән артмаган Татарстан Республикасында студентларның хезмәт отрядларына булышлык күрсәтүгә һәм аларны үстерүгә юнәлтелгән социаль әһәмияттәге проект булган берлән артмаган заявка тапшыра.

2.5. КБО әлеге Тәртипнең 2.3 пунктындагы «б» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта вәкаләтле орган әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә соратып ала.

2.6. Документлар кабул итү конкурс үткәрелү турында мәгълүмат сайтта урнаштырылган көннән соң 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

2.7. Әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документларын кабул итү һәм теркәү алар кергән көнне вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.8. Конкурста катнашу өчен бирелгән заявкалар аларнын кабул итү тәмамланган көннән соң календарь көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә әлеге тәртиптә билгеләнгән таләпләр нигезендә конкурс комиссиясе тарафыннан карап тикшерелә.

2.9. Конкурста катнашуга әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган КБО катнашырга рөхсәт ителә, әмма конкурста катнашуга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәге нигезләр булмаганда:

а) әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы күләмендә тапшырмау, әлеге Тәртипнең 2.3 пунктындагы «б» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән документлардан тыш;

б) документларның әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве4

в) документларны заявкалар бирү вакыты узганнан соң тапшыру;

г) КБО әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү.

2.10. Конкурста катнашучылар исемлеге, шулай ук конкурста катнашуга рөхсәт бирүдән баш тартылган КБО исемлеге (алга таба – исемлекләр) алар расланган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә сайтта урнаштырыла.

2.11. Конкурста катнашу рөхсәт ителмәгән КБО хәбәр итү исемлекләр расланган көннән соң өч көн эчендә вәкаләтле орган тарафыннан өстәмә рәвештә хәбәр итү кәгазе җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.12. Конкурста катнашучыларның заявкалары исемлекләр расланган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә конкурс комиссиясе әгъзаларына карап тикшерү өчен җибәрелә. Конкурс комиссиясе әгъзалары аларга заявкалар тапшырылган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә заявкаларны һәм аларга теркәлгән документларны әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада әйтелгән критерийлар нигезендә бәялиләр.

2.13. Конкурс комиссиясе конкурс җиңүчеләрен түбәндәге номинацияләрдә билгели:

а) Татарстан Республикасында эшчәнлек төрләре буенча студентлар отрядларын үстерү (төзелеш, педагогика, археология, сервис, авыл хуҗалыгы, энергетика, медицина, путин, экология отрядлары, урман фондын төзекләндерү отрядлары, ерак юлга йөри торган поезд вагоннарын озата баручылар);

б) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә күп профильле студентлар хезмәт отрядларын үстерү;

в) Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекләрен гамәлгә ашыра торган югары белемнең белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында күп профильле студентлар хезмәт отрядларын үстерү.

2.14. Конкурс комиссиясе заявкаларны бәяләү тәмамланган көннән соң өч көн эчендә һәм номинация буенча заявкалар рейтингын төзи. Заявкалар рейтингы заявкаларны бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурста катнашучылар җыйган баллар суммасы нигезендә төзелә.

2.15. Конкурс җиңүчеләрен билгеләү конкурс комиссиясе утырышында заявкалар рейтингы нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе утырышында аның әгъзаларының кимендә 2 / 3 катнашса, ул тулы хокуклы булып санала. Комиссия карары өчен утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч була. Конкурс комиссиясе утырышында рәис катнашмаса, аның вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара. Һәр номинациядә заявкалары иң күп санда балл җыйган конкурста катнашучылар конкурсның җиңүчеләре була.

2.16. Конкурс җиңүчеләрен билгеләү буенча конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе конкурс комиссиясе утырышы үткәрелгән көннән соң бер эш көне эчендә рәсмиләштерелә, комиссия рәисе яисә аның утырышта комиссия рәисе вазыйфаларын башкарган урынбасары һәм конкурс комиссиясенең җаваплы секретары тарафыннан имзалана.

2.17. Вәкаләтле орган конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе нигезендә конкурс җиңүчеләре исемлеген раслый һәм грантлар бирү турында карар кабул итә.

2.18. Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат конкурс җиңүчеләр исемлеге расланган көннән соң өч көн эчендә сайтта урнаштырыла.

## 3. Грантлар түләү тәртибе

3.1. Грантлар бирү турыда вәкаләтле орган карары вәкаләтле орган һәм конкурс җиңүчесе дип танылган КБО арасында килешү (алга таба – килешү) төзү өчен нигез булып тора.

3.2. Килешү конкурс йомгаклары турында мәгълүмат сайтта урнаштырылган көннән соң 10 көн эчендә төзелә.

3.3. Килешүнең формасын вәкаләтле орган раслый.

3.4. Килешүдә грантның күләме, анық максатчан билгеләнеше, грантның хисап финанс елында файдаланылмаган өлешен грант алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары һәм тәртипләре, грантны файдалану турында хисап бирү тәртибе, вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан грант алучының грант бирү шартларны, максатын һәм тәртибен, грант алучы тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын саклау турында нигезләмәне үтәүгә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга грант алучының ризалыгы күздә тотыла.

3.5. Вәкаләтле орган грантны килешү төзелгән көннән соң 10 көн эчендә грант алучының исәп-хисап счетына күчерә.

## 4. Гранттан файдалануны тикшерүдә тоту

4.1. Грант алучы вәкаләтле органга вәкаләтле орган раслаган форма буенча һәм килешүдә каралган тәртиптә гранттан файдалану турында хисап тапшыра, шулай ук вәкаләтле органга тапшыра торган белешмәләрнең дөреслеге өчен законнар нигезендә җавап тота.

4.2. Түбәндәге очракларда вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң 30 көн эчендә грант алучы тарафыннан грант Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

а) грант алучы тарафыннан грант бирү шартларын үтәмәү;

б) грантны максатчан файдаланмау.

4.3. Килешүләрдә каралаган очракларда грантның хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

4.4. Грант алучы тарафыннан грантны кире кайтару вакытлары бозылганда вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 4.2 һәм 4.3 пунктларында билгеләнгән вакыт узган көннән соң җиде көн эчендә әлеге акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча чаралар күрә.

4.5. Грант акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кайтарудан баш тартылган очракта алар законнар нигезендә мәҗбүри кайтартылырга тиеш.

4.6. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы грант алучының грантны тапшыру шартлары, максатларын һәм тәртибен тикшерүне гамәлгә ашыра.

4.7. Грантны максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тотуны законнар нигезендә вәкаләтле орган гамәлгә ашыра.

---